БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
9 август 2023 ел

**КАРАР**
№ 198

**«2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2023 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1300596,91 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1346848,49 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 46251,58 мең сум итеп».

1.2. Карарның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 15 нче кушымтасы нигезендә 2023 елда 938437,19 мең сум итеп;

- әлеге карарның 16 нче кушымтасы нигезендә 2024 елда 845333,55 мең сум һәм 2025 елда 854168,97 мең сум итеп.»

1.3. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2023 елга 20840,67 мең сум, 2024 елга 17200,00 мең

сум, 2025 елга 17800,00 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2023, 2024 һәм 2025 елларда Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.».

1.4. Әлеге карарның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, кушымталары нигезендә «2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 5нче, 7 нче, 15 нче, 17 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин